ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 182 2017 елның 20 марты

Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 6 июнендәге 1094 номерлы «Түбән Кама муниципаль районында 2014-2016 елларга муниципаль хезмәтне үстерү» муниципаль программасын раслау турында» карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, «2014-2019 елларга Татарстан Республикасында дәүләт граждан хезмәтен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне үстерү» дәүләт программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 22 ноябрендәге 910 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Советының 2016 елның 21 мартындагы 12 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы нигезләмә белән карар бирәм:

1. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 6 июнендә кабул ителгән 1094 номерлы «Түбән Кама муниципаль районында 2014-2016 елларга муниципаль хезмәтне үстерү» муниципаль программасын раслау турында» карарына кушымта нигезендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.

2. Түбән Кама муниципаль районы җирле үзидарә органнарына әлеге карарга кушымта тарафыннан кертелә торган үзгәрешләргә туры китерү максатларында локаль хокукый актларны эшләп бетерергә тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

2. Рекомендовать органам местного самоуправления Нижнекамского муниципального района доработать локальные правовые акты в целях их приведения в соответствие с изменениями, вносимыми приложением к настоящему постановлению.

А.Г. Сәйфетдинов

Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы
Башкарма комитетының
2017 елның 20 мартындагы
182 номерлы карары белән расланган
кушымта

Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының
2014 елның 6 июнендәге 1094 номерлы «Түбән Кама муниципаль районында 2014-2016 елларга муниципаль хезмәтне үстерү» муниципаль программасын раслау турында» карарына үзгәрешләр

1. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 6 июнендәге 1094 номерлы «Түбән Кама муниципаль районында 2014-2016 елларга муниципаль хезмәтне үстерү» муниципаль программасын раслау турында» карарында:

1.1. исемендә «2014-2016» саннарын «2014-2019» саннарына алмаштырырга;

1.2. 1 пунктта «2014-2016» саннарын «2014-2019» саннарына алмаштырырга.

2. Карар белән расланган «Түбән Кама муниципаль районында 2014-2016 елларга муниципаль хезмәтне үстерү» муниципаль программасында «(алга таба - Программа):

2.1. исемендә «2014-2016» саннарын «2014-2019» саннарына алмаштырырга;

2.2. «Программа паспорты» бүлегендә:

2.2.1. «Программа исеме», «Программаны гамәлгә ашыру сроклары» юлларында «2014-2016» саннарын «2014-2019» саннарына алмаштырырга;

2.2.2. «Еллар буенча бүлгәләнгән Программаны финанслау күләме» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Программаны финанслауның гомуми күләме Түбән Кама муниципаль районы һәм Татарстан Республикасы бюджетлары хисабына 3 419 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:

2014 нче елда - 499 мең сум;

2015 нче елда - 524 мең сум;

2016 нчы елда - 550 мең сум;

2017 нче елда - 580 мең сум;

2018 нче елда - 614 мең сум;

2019 нчы елда - 652 мең сум.»;

2.2.3. «Программаны гамәлгә ашыруның көтелгән ахыргы нәтиҗәләре» юлында:

2.2.3.1. беренче абзацта «2017» санын «2020» санына алмаштырырга;

2.2.3.2 5 пунктта «һөнәри белем һәм күнекмәләр» сүзләрен сүзләрен «белем һәм күнекмәләр» сүзләренә алмаштырырга;

2.2.3.3. 12 пунктына «, Татарстан Республикасы дәүләт органнары Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары өчен Карьера порталын формалаштыруда җирле үзидарә органнарының катнашуын тәэмин итү» сүзләрен өстәргә;

2.2.3.4. түбәндәге эчтәлекле 13-14 пунктлар өстәргә:

«13. Эшчәнлек нәтиҗәлелегенең билгеләнгән төп күрсәткечләренә ирешүгә бәйле рәвештә, муниципаль хезмәткәрләрне матди стимуллаштыруны гамәлгә ашырырга.

14. Җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә үзләренә беркетелгән функцияләр һәм вәкаләтләр кысаларында башкарыла торган процессларны тасвирлау стандартларын кертергә.»;

2.3. «II. Программаның максатлары, бурычлары һәм Программаның чаралар исемлеге» бүлегендә:

2.3.1. 7 пунктның абзацында:

2.3.1.1. «2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.3.1.2. «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне үстерү мәсьәләләре комиссиясе турында» Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 11 октябрендәге ПУ-680 номерлы Указы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы кадрлар сәясәте мәсьәләләре советы турында» Татарстан Республикасы Президентының 2014 елның 12 июнендәге ПУ-569 номерлы Указы» сүзләренә алмаштырырга;

2.3.1.3. «2014-2016» саннарын «2014-2019» саннарына алмаштырырга;

2.3.2. 7 пунктның 3 абзацында «2014-2016» саннарын «2014-2019» саннарына алмаштырырга;

2.4. бүлек «III. Программаны ресурслар белән тәэмин итүне нигезләү» бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. Программаны ресурслар белән тәэмин итүне нигезләү

Программа чаралары Түбән Кама муниципаль районы бюджеты хисабына тормышка ашырыла. 2014-2019 елларга Программаны финанслау күләме 3 419 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:

2014 нче елда-499 мең сум;

2015 нче елда-524 мең сум;

2016 нчы елда-550 мең сум;

2017 нче елда-580 мең сум;

2018 нче елда-614 мең сум;

2019 нчы елда-652 мең сум.

«2014-2019 елларга Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне үстерү» дәүләт программасын гамәлгә ашыру кысаларында гамәлгә ашырыла торган Программа чаралары Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән күрсәтелгән дәүләт программасында каралган ассигнованиеләр күләмендә финанслана.

Бюджет мөмкинлекләрен исәпкә алып, Программаны гамәлгә ашыруга юнәлтелә торган акчалар күләме чираттагы финанс елына Түбән Кама муниципаль районы бюджеты проектын эшләгәндә аныклана.»;

2.5. «V. Программаның икътисадый һәм социаль нәтиҗәлелеген бәяләү» бүлегенә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Программаның нәтиҗәлелеген бәяләү аны гамәлгә ашыруның бөтен чорында 1 нче һәм 2 нче кушымталарда китерелгән Программаның нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары 2020 елга күрсәткечләргә ирешүне исәпкә алып башкарыла.».

3. Программага кушымтада:

3.1. исемендә «2014-2016» саннарын «2014-2019» саннарына алмаштырырга;

3.2. «I. Оештыру һәм норматив-хокукый характердагы, максатчан финанслауны таләп итми торган чаралар» бүлегендә:

3.2.1. «Төп чараларны башкару сроклары» баганасының 1 пунктында «2014-2016» саннарын «2014-2019» саннарына алмаштырырга;

3.2.2. «Төп чараның исеме» баганасының 4 пунктында «һөнәри белемнәр һәм күнекмәләр» сүзләрен «белемнәр һәм күнекмәләр» сүзләренә алмаштырырга;

3.2.3. «Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары» баганасының 4 пунктында «һөнәри белем һәм күнекмәләр» сүзләрен «белемнәр һәм күнекмәләр» сүзләренә алмаштырырга;

3.2.4. «Төп чараларны үтәү сроклары» баганасының 5 пунктында «2014-2016» саннарын «2014-2019» саннарына алмаштырырга;

3.2.5. «Төп чараларны үтәү сроклары» баганасының 7 пунктында «2014-2016» саннарын «2014-2019» саннарына алмаштырырга;

3.2.6. «Төп чараларны үтәү сроклары» баганасының 8 пунктында «2014-2016» санна-рын «2014-2019» саннарына алмаштырырга;

3.3. «II. Максатчан финанслауны таләп итә торган чаралар» бүлегендә:

3.3.1. «Төп чараларны башкару сроклары» баганасының 1 пунктында «2014-2016» саннарын «2014-2019» саннарына алмаштырырга;

3.3.2. «Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары» баганасының 1 пунктында «2016-33%» саннарыннан соң «2017-33%, 2018-33%, 2019-33%» саннарын өстәргә;

3.3.3. «Төп чараларны үтәү сроклары» баганасының 2 пунктында «2014-2016» саннарын «2014-2019» саннарына алмаштырырга;

3.3.4. «Төп чараларны үтәү сроклары» баганасының 3 пунктында «2014-2016» саннарын «2014-2019» саннарына алмаштырырга;

4. Программаны 2 нче кушымта белән тулыландырырга (кушымта итеп бирелә).

Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы
Башкарма комитетының
2017 елның 20 мартындагы
182 номерлы карары белән расланган
кушымта

«2014-2019 елларга Түбән Кама муниципаль
районында муниципаль хезмәтнең үсеше»
Муниципаль программасына
2 нче кушымта

«2014-2019 елларга Түбән Кама муниципаль районында муниципаль хезмәтнең үсеше»
Муниципаль программасының максатларын һәм бурычларын гамәлгә ашыру буенча чаралар һәм 2017 елдан 2019 елга кадәр чорга аларның нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары

| т/с | төп<br>чараның исеме | Башкару<br>чылар | Үтәү<br>срокл<br>ары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары | Индикаторларның кыйммәте | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2013 ел (төп) | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| I. Максатчан финанслауны таләп итми торган оештыру һәм норматив-хокукый характердагы чаралар, аларның нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары | | | | | | | | |
| Максаты: «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы җирле үзидарә органнары (алга таба – җирле үзидарә органнары) үзләренә йөкләнгән вәкаләтләрне үтәүнең нәтиҗәлелеген арттыру» | | | | | | | | |
| Бурычы: «Җирле үзидарә органнары аппаратлары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыру, шул исәптән аларның оештыру структурасын һәм штат санын камилләштерү аша» | | | | | | | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Муниципаль хезмәткәрләр эшчәнлеге нәтиҗәлелегенең төп күрсәткечләре буенча тәкъдимнәр әзерләү | Җирле үзидарә органнары, оештыру-кадрлар бүлеге | 2017-2019 еллар | Формалаштырылган муниципаль хезмәткәрләр эшчәнлегенең нәтиҗәлелегә күрсәткечләре | - | + | + | + |
| 2. | Җирле үзидарә органнары структурасы стандартларын кертү | Җирле үзидарә органнары, оештыру-кадрлар бүлеге | 2018-2019 еллар | Җирле үзидарә органнары структурасы стандартларына туры китерелгән җирле үзидарә органнары структурасы | - | - | + | + |
| 3. | Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт кадрлар составының бердәм мәгълүмат системасында кадрлар эшен алып баруны тәэмин итү | Җирле үзидарә органнары, оештыру-кадрлар бүлеге | 2017-2019 еллар | Җирле үзидарә органнарының кадрлар составын характерлый торган актуаль мәгълүматларның Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт кадрлар составының бердәм мәгълүмат системасында булуы | - | + | + | + |
| | Бурычы: «Муниципаль хезмәткәрләр хезмәтенә сайлап алу, комплекслы бәяләү һәм аны алга этәрүнең нәтиҗәле механизмнарын гамәлгә кертү» | | | | | | | |
| 4. | Муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфалары турында мәгълүматны муниципаль берәмлекнең рәсми сайтында һәм «Дәүләт хезмәте һәм идарә кадрларының федераль порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында урнаштыру | Җирле үзидарә органнары, оештыру-кадрлар бүлеге, җәмәгатьчелек һәм ММЧ | 2017-2019 еллар | Муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфалары турында мәгълүмат булу:<br>1) муниципаль берәмлекнең рәсми сайтында;<br>2) «Дәүләт хезмәтенең һәм идарә кадрларының федераль порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында | - | + | + | + |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | белән элемтә бүлеге | | | | | | |
| Бурычы:«Муниципаль хезмәткә яшь, перспективалы белгечләрне җәлеп итү һәм беркетү» | | | | | | | | |
| 5. | Массакүләм мәгълүмат чараларында, «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрләрендә җирле үзидарә органнарының рәсми сайтларында муниципаль берәмлекләр эшчәнлеге турында мәгълүмат бастырып чыгару | Җирле үзидарә органнары, оештыру-кадрлар бүлеге, җәмәгать челек һәм ММЧ белән элемтә бүлеге | 2014-2019 еллар | Массакүләм мәгълүмат чараларында, «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрләрендә җирле үзидарә органнарының рәсми сайтларында урнаштырылган муниципаль хезмәткәрләр эшчәнлеге, муниципаль хезмәтне үстерү турында мәкаләләр һәм бүтән мәгълүмати-аналитик материаллар саны | 4 | 15 | 15 | 15 |
| Бурычы: «Җәмәгать контроле системасын һәм гражданлык җәмгыяте институтлары белән хезмәттәшлекне үстерү, муниципаль хезмәттә коррупциягә каршы көрәш чараларын гамәлгә ашыру» | | | | | | | | |
| 6. | Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъвачылар тарафыннан аны үтүгә бәйле таләпләрне һәм чикләүләрне үтәүне тикшерүне гамәлгә ашыру | Җирле үзидарә органнары, оештыру-кадрлар бүлеге | 2017-2019 еллар | Үткәрелгән тикшерү чаралары саны | - | + | + | + |
| II. «Түбән Кама муниципаль районында 2014-2016 елларга муниципаль хезмәтне үстерү» муниципаль программасы чаралары максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары һәм аларны финанслау»* | | | | | | | | |
| Максаты «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан аларга йөкләнгән вәкаләтләрне үтәүнең нәтиҗәлелеген арттыру» | | | | | | | | |
| Бурыч: «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең (алга таба – | | | | | | | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | муниципаль хезмәткәрләр), шулай ук күрсәтелгән җирле үзидарә органнарының кадр резервларына кертелгән затларның һөнәри һәм идарә компетентлыгын үстерү» | | | | | | | |
| 1. | Муниципаль хезмәткәрләрнең (муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның) квалификациясен күтәрүне, һөнәри белемен арттыруны оештыру | Җирле үзидарә органнары, оештыру-кадрлар бүлеге | 2017-2019 еллар | Әлеге елда квалификация күтәрүне, һөнәри белемен арттыруны узган муниципаль хезмәткәрләр (муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар) өлеше | 33% | 33% | 33% | 33% |
| 2. | Кадрлар резервларына кертелгән затларны әзерләүне (укытуны, стажировкаларын) оештыру | Җирле үзидарә орган-нары, оештыру-кадрлар бүлеге | 2017-2019 еллар | Кадрлар резервларына кертелгән затларның гомуми саныннан (арта баручы нәтиҗә) кадрлар резервына кертелгән һәм әзерлек (укыту, стажировка) узган затлар өлеше | 10% | 100% | 100% | 100% |
| 3. | «2014-2019 елларга Татар-стан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен һәм Та-тарстан Республикасында муниципаль хезмәтне үстерү» дәүләт программа-сы чаралары кысаларында Россия һәм чит ил бел-гечләрен җәлеп итү белән семинарлар, киңәшмәләр, башка чаралар оештыруда катнашу | Җирле үзидарә орган нары, оештыру-кадрлар бүлеге | 2017-2019 еллар | Муниципаль хезмәт мәсьәләләре буенча үткәрелгән семинарларда, киңәшмәләрдә, конференцияләрдә катнашу | - | + | + | + |
| 4. | «2014-2019 елларга Татар-стан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен һәм Та- | Җирле үзидарә орган | 2017-2019 еллар | «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Советы» ассоциациясенә үткәрелә торган укуларның сыйфаты, муниципаль хезмәткәрләрне укытуны камилләштерү буенча | - | + | + | + |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | тарстан Республикасында муниципаль хезмәтне үстерү» дәүләт программасы чаралары кысаларында муниципаль хезмәткәрләрне укыту нәтиҗәлелеге мониторингында катнашу | нары, оештыру-кадрлар бүлеге | | тәкъдимнәр турында мәгълүмат җибәрү | | | | |

* «2014-2016 елларга Түбән Кама муниципаль районында муниципаль хезмәтне үстерү» муниципаль программасы чараларын финанслау әлеге Программаның III бүлегендә каралган күләмнәрдә гамәлгә ашырыла. «2014-2019 елларга Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне үстерү» дәүләт программасын тормышка ашыру кысаларында гамәлгә ашырыла торган программалар Татарстан Республикасы бюджеты чаралары исәбенә күрсәтелгән дәүләт программасында каралган ассигнованиеләр күләмендә финанслана.